| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ 30.09.2022 1279 КАРАР

Алабуга муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм йөк ташуның муниципаль маршрутлары буенча транспорт чаралары хәрәкәте расписаниесен раслау турында

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон,«Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы» 2007 елның 8 декабрендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1.Алабуга муниципаль районы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм йөк ташуның муниципаль маршрутлары буенча транспорт чаралары хәрәкәте расписаниесен расларга (1 нче кушымта).

2.Алабуга муниципаль районы Алабуга шәһәре Башкарма комитетының: «Алабуга муниципаль районында һәм Алабуга шәһәрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары буенча транспорт чаралары хәрәкәте расписаниесен раслау турында» 2019 елның 17 июнендәге 15 номерлы һәм «Алабуга муниципаль районында һәм Алабуга шәһәрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары буенча транспорт чаралары хәрәкәте

расписаниесен раслау турында» 2020 елның 2 июлендәге 20 номерлы карарларын гамәлдән чыгарырга.

3.Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районында һәм Алабуга шәһәрендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципальара маршрутлары буенча транспорт чаралары хәрәкәте расписаниесен раслау турында» 2022 елның 20 апрелендәге 511 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

4. Әлеге карарның 1 пункты рәсми басылып чыккан көненнән 30 көн узгач үз көченә керә.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

6.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 5DD9ADE894A62EB7F6C4DA0DBC7098E466BA

Владелец: Нургаянов Ленар Фаридович

Действителен с 03.12.2021 до 03.03.2023